**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О государственной информационной системе Республики Татарстан «Система планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан»

В целях повышения эффективности государственного управления, совершенствования системы планирования и организации мероприятий в Республике Татарстан с использованием информационно-телекоммуникационных технологий **постановляю**:

1. Создать государственную информационную систему Республики Татарстан «Система планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан» (далее также – государственная информационная система Республики Татарстан).

2. Утвердить Положение о государственной информационной системе Республики Татарстан «Система планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан» (прилагается).

3. Определить:

Министерство информатизации и связи Республики Татарстан государственным заказчиком государственной информационной системы Республики Татарстан;

Аппарат Президента Республики Татарстан функциональным администратором государственной информационной системы Республики Татарстан;

государственное унитарное предприятие Республики Татарстан «Центр информационных технологий Республики Татарстан» техническим оператором государственной информационной системы Республики Татарстан.

4. Руководителю Аппарата Президента Республики Татарстан:

утвердить регламент функционирования государственной информационной системы Республики Татарстан;

обеспечить в месячный срок совместно с Министерством информатизации и связи Республики Татарстан и государственным

унитарным предприятием Республики Татарстан «Центр информационных технологий Республики Татарстан» введение государственной информационной системы Республики Татарстан в эксплуатацию;

внести предложения по приведению актов Президента Республики Татарстан в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения по его реализации.

5. Кабинету Министров Республики Татарстан:

ежегодно предусматривать финансирование работ по поддержке и развитию государственной информационной системы Республики Татарстан;

привести свои нормативные правовые акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения по его реализации.

6. Предложить государственным органам Республики Татарстан, не являющимся исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, территориальным органам федеральных органов исполнительной власти, органам местного самоуправления в Республике Татарстан использовать в своей деятельности государственную информационную систему Республики Татарстан.

7. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
19 ноября 2015 года
№ УП-1112

Утверждено
Указом Президента
Республики Татарстан

от « 19 » ноября 2015 года

№ УП- 1112

**Положение**
**о государственной информационной системе Республики Татарстан «Система планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан»**

## I. Общие положения

1. Настоящее Положение определяет цели создания, структуру государственной информационной системы Республики Татарстан «Система планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан» (далее – государственная информационная система Республики Татарстан), порядок доступа к ней, а также порядок управления государственной информационной системой Республики Татарстан.

2. Правовой основой создания и эксплуатации государственной информационной системы Республики Татарстан являются законы и иные нормативные правовые акты Российской Федерации и Республики Татарстан, а также настоящее Положение.

## II. Цели создания государственной информационной системы Республики Татарстан

3. Целями создания государственной информационной системы Республики Татарстан являются:

внедрение информационно-телекоммуникационных технологий в процессы планирования, организации и контроля мероприятий, проводимых государственными органами, органами местного самоуправления, подведомственными им организациями или с участием их представителей (далее – мероприятия), в Республике Татарстан;

совершенствование механизмов контроля процессов планирования и организации мероприятий в Республике Татарстан.

## III. Структура государственной информационной системы Республики Татарстан

4. В государственную информационную систему Республики Татарстан

включается информация о мероприятиях:

Президента Республики Татарстан;

Премьер-министра Республики Татарстан;

Кабинета Министров Республики Татарстан;

республиканских органов исполнительной власти и подведомственных им организаций.

5. По инициативе Государственного Совета Республики Татарстан, иных государственных органов Республики Татарстан, не являющихся исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления информация об их мероприятиях включается в государственную информационную систему Республики Татарстан.

6. По инициативе территориальных органов федеральных органов исполнительной власти в Республике Татарстан, иных государственных органов и организаций (за исключением перечисленных в пунктах 4 и 5 настоящего Положения) информация об их мероприятиях может включаться в государственную информационную систему Республики Татарстан по решению функционального администратора государственной информационной системы Республики Татарстан.

7. Государственная информационная система Республики Татарстан состоит из следующих модулей:

модуль мероприятий, представляющий собой форму отображения и внесения информации о мероприятиях в государственную информационную систему Республики Татарстан;

модуль поиска, представляющий собой инструмент обеспечения поиска мероприятий, информация о которых включена в государственную информационную систему Республики Татарстан, по заданным критериям;

модуль планирования, представляющий собой инструмент сведения мероприятий, информация о которых включена в государственную информационную систему Республики Татарстан, в единый республиканский бюллетень мероприятий;

модуль уведомлений, представляющий собой инструмент обеспечения доставки уведомлений пользователям государственной информационной системы Республики Татарстан об изменениях в мероприятиях, о назначении ответственных за проведение мероприятий, об изменении перечня участников мероприятий и об иной значимой информации о мероприятиях.

## IV. Доступ к государственной информационной системе Республики Татарстан

8. Доступ к государственной информационной системе Республики Татарстан и данные для аутентификации пользователям системы предоставляются техническим оператором.

9. Доступ к информационным ресурсам, размещенным в государственной информационной системе Республики Татарстан, осуществляется на безвозмездной основе.

10. Доступ пользователей к государственной информационной системе

Республики Татарстан осуществляется посредством авторизованного доступа с учетом профиля пользователя в соответствии с регламентом функционирования государственной информационной системы Республики Татарстан через информационно-телекоммуникационную сеть «Интернет» по адресу: calendar.tatarstan.ru.

## V. Управление государственной информационной системой Республики Татарстан

11. Функциональный администратор государственной информационной системы Республики Татарстан:

устанавливает правила и порядок функционирования государственной информационной системы Республики Татарстан (регламент функционирования государственной информационной системы Республики Татарстан);

обеспечивает развитие государственной информационной системы Республики Татарстан, в том числе совершенствование ее структуры, функций и содержания;

обеспечивает мониторинг работы пользователей государственной информационной системы Республики Татарстан, формирование и представление статистических и аналитических отчетов о функционировании государственной информационной системы Республики Татарстан.

12. Технический оператор государственной информационной системы Республики Татарстан обеспечивает бесперебойное функционирование аппаратно-программного комплекса государственной информационной системы Республики Татарстан, а также его развитие и модернизацию в соответствии с потребностями, определенными функциональным администратором государственной информационной системы Республики Татарстан.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында**

Дәүләт идарәсе нәтиҗәлелеген арттыру, мәгълүмати-телекоммуникация технологияләрен файдаланып, Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм оештыру системасын камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы) булдырырга.

2. «Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне расларга (кушымтада бирелә).

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы дәүләт заказчысы итеп;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратын Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы функциональ администраторы итеп;

«Татарстан Республикасы мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесен Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының техник операторы итеп.

4. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә:

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының гамәле регламентын расларга;

бер ай эчендә Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе белән бергәләп

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын файдалануга кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Президенты актларын әлеге Указга туры китерү буенча тәкъдимнәр кертергә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

ел саен Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын алып бару һәм үстерү эшләрен финанслауны күздә тотарга;

үз норматив хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары булмаган Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, федераль башкарма хакимиятнең территориаль органнарына, Татарстан Республикасында җирле хакимият органнарына үз эшчәнлекләрендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалануны тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 19 ноябрь
№ ПУ-1112

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның « 19 » ноябрендәге
ПУ- 1112 номерлы Указы белән
расланды

**«Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмәдә «Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы) булдыру максатлары, аның структурасы, аннан файдалану тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы белән идарә итү тәртибе билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын булдыру һәм аны эксплуатацияләүгә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә хокукый нигез булып тора.

## II. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын булдыру максатлары

3. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын булдыру максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасында мәгълүмати-телекоммуникация технологияләрен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, аларга караган оешмалар тарафыннан яисә аларның вәкилләре катнашында уздырыла торган чараларны (алга таба – чаралар) планлаштыру, оештыру һәм контроль процессларына кертү;

Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм оештыру процессларын контрольдә тоту механизмнарын камилләштерү.

## III. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы структурасы

4. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына түбәндәгеләр уздырган чаралар турында мәгълүмат урнаштырыла:

Татарстан Республикасы Президенты;

Татарстан Республикасы Премьер-министры;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

республика башкарма хакимият органнары һәм аларга караган оешмалар.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары булмаган башка Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары инициативасы буенча аларның чаралары турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелә.

6. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалары (әлеге Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында санап кителгән пунктлардан тыш) инициативасы белән аларның чаралары турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы функциональ операторы карары белән Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелергә мөмкин.

7. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы түбәндәге модульләрдән тора:

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасында чагылдырылучы һәм аңа кертелүче мәгълүмат рәвешендәге чаралар модуле;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасына алар турында мәгълүмат урнаштырылган чараларны бирелгән критерийлар буенча эзләүне тәэмин итү инструменты рәвешендәге эзләү модуле;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына алар турында мәгълүмат урнаштырылган чараларны бердәм республика чаралар бюллетененә җыю инструменты рәвешендәге планлаштыру модуле;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучыларга чаралардагы үзгәрешләр, чараларны уздыру өчен җаваплыларны билгеләү турында, чарада катнашучылар исемлеге үзгәрү турында хәбәрнамәләр һәм чаралар турында башка әһәмиятле мәгълүматлар җиткерүне тәэмин итү инструменты рәвешендәге хәбәрнамәләр модуле.

## IV. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалану мөмкинлеге

8. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалану мөмкинлеге һәм аутентификация мәгълүматлары системадан файдаланучыларга техник оператор тарафыннан бирелә.

9. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган мәгълүмати ресурслардан файдалану түләүсез башкарыла.

10. Файдаланучыларның Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керүе Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының гамәле регламентына нигезләнеп, файдаланучы профиле исәпкә алынган автор буларак рөхсәт алып «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша calendar.tatarstan.ru адресында башкарыла.

## V. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына идарә итү

11. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының функциональ администраторы түбәндәгеләрне башкара:

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының гамәле кагыйдәләрен һәм тәртибен (Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы гамәле регламентын) билгели;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы үсешен, шул исәптән аның структурасын, функцияләрен һәм эчтәлеген камилләштерүне тәэмин итә;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучылар эшен мониторинглауны, Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы гамәле турында статистик һәм аналитик хисаплар тутыруны һәм бирүне тәэмин итә.

12. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы техник операторы Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы аппарат-программа комплексының өзлексез эшләвен, шулай ук аның үсешен һәм яңартылуын Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының функциональ администраторы тарафыннан билгеләнгән ихтыяҗлар нигезендә тәэмин итә.